КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 17 февраль г.Казань № 123

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм аларның ведомство буйсынуындагы учреждениеләренә хезмәт күрсәтә торган транспорт чараларының норматив саны, үткән юлы һәм аларны агымдагы карап тоту чыгымнары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актлары үз көчен югалткан дип санау турында» 2018 ел, 1 декабрь, 1073 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм аларның ведомство буйсынуындагы учреждениеләренә хезмәт күрсәтә торган транспорт чараларының норматив саны, үткән юлы һәм аларны агымдагы карап тоту чыгымнары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актлары үз көчен югалткан дип санау турында» 2018 ел, 1 декабрь, 1073 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 7 март, 165 нче; 2019 ел, 17 май, 402 нче; 2019 ел, 13 июль, 572 нче, 2019 ел, 02 ноябрь, 1006 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы һәм аның карамагындагы учреждениеләр өчен транспорт чаралары (иң чик санда) белән тәэмин итү һәм транспорт чараларының норматив йөгереше нормативларында:

түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «6. | «Татарстан Республикасының пространство мәгълүматлары фонды» дәүләт бюджет учреждениесе | | 1 | җиңел автомобиль | 32 805 | 135»; |

«Барысы» юлында «55» саннарын «56» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы һәм аның карамагындагы учреждениеләр өчен транспорт чаралары (иң чик санда) белән тәэмин итү һәм транспорт чараларының норматив йөгереше нормативларында:

түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «5. | «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе | | 12 | җиңел автомобиль | 32 805 | 135 |
| | | | 1 | микроавтобус/фургон | 32 805 | 135»; |

«Барысы» юлында «17» саннарын «30» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы, аның территориаль органнары һәм аның карамагындагы учреждениеләр өчен транспорт чаралары (иң чик санда) белән тәэмин итү һәм транспорт чараларының норматив йөгереше нормативларында:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «1. | Министрлык аппараты | министр | 2 | җиңел автомобиль | нормага салынмаган | нормага салынмаган |
| | | министрның беренче урынбасары | 1 | җиңел автомобиль | 32 805 | 135 |
| | | министр урынбасарлары | 3 | җиңел автомобиль | 32 805 | 135 |
| | | оператив автомобиль | 3 | җиңел автомобиль | 32 805 | 135»; |

«Барысы» юлында «39» саннарын «40» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы һәм аның карамагындагы учреждениеләр өчен транспорт чаралары (иң чик санда) белән тәэмин итү һәм транспорт чараларының норматив йөгереше нормативларында:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «6. | «Патриот» яшьләрне спорт-патриотик һәм армиягә кадәр әзерләү республика үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесе | | 1 | җиңел автомобиль | 17 010 | 70 |
| | | | 2 | микроавтобус/фургон | 17 010 | 70»; |

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы һәм аның карамагындагы учреждениеләр өчен транспорт чаралары (иң чик санда) белән тәэмин итү һәм транспорт чараларының норматив йөгереше нормативларында:

1 пунктта 4 графада «6» санын «7» санына алмаштырырга;
«Барысы» юлында «115» саннарын «116» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы һәм аның карамагындагы учреждениеләр өчен транспорт чаралары (иң чик санда) белән тәэмин итү һәм транспорт чараларының норматив йөгереше нормативларында 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «2. | «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе | | 42 | җиңел автомобиль | 32 805 | 135 |
| | | | 1 | микроавтобус/фургон | 65 610 | 270»; |

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы һәм аның карамагындагы учреждениеләр өчен транспорт чаралары (иң чик санда) белән тәэмин итү һәм транспорт чараларының норматив йөгереше нормативларында:

9 пунктның 6 графасында «32 805» саннарын «36 450» саннарына алмаштырырга;
9 пунктның 7 графасында «135» саннарын «150» саннарына алмаштырырга;
әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы һәм аның карамагындагы учреждениеләр өчен транспорт чаралары (иң чик санда) белән тәэмин итү һәм транспорт чараларының норматив йөгереше нормативларында:
1 пунктның 4 графасында «4» санын «5» санына алмаштырырга;
3 пунктны төшереп калдырырга;
«Барысы» юлында «24» саннарын «12» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт комитетлары һәм алар карамагындагы учреждениеләр өчен транспорт чаралары (иң чик санда) белән тәэмин итү һәм транспорт чараларының норматив йөгереше нормативларының «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Дәүләт комитеты аппараты | рәис | 1 | җиңел автомобиль | 32 805 | 135 |
| | | рәиснең беренче урынбасары | 1 | җиңел автомобиль | 32 805 | 135 |
| | | рәис урынбасары | 3 | җиңел автомобиль | 32 805 | 135 |
| | | кизү | 2 | җиңел автомобиль | 32 805 | 135 |
| | Барысы | | 7»; | | | |

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы ведомстволары һәм алар карамагындагы учреждениеләр өчен транспорт чаралары (иң чик санда) белән тәэмин итү һәм транспорт чараларының норматив йөгереше нормативларында:

«Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе» бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «3. | «Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе эшчәнлеген тәэмин итү идарәсе» Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесе | | 1 | җиңел автомобиль | 32 805 | 135»; |

«Барысы» юлында «20» саннарын «21» саннарына алмаштырырга.

Татарстан Республикасы<br>Премьер-министры　　　　　　　　　　　　　　　　　　А.В.Песошин